
Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



6

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮНЬ * 2024 * КАЗАН

Игорь КИЙКО



Алмаз ХӘМЗИН

СЫКРАУ

Сагынасыз микән сез, замандашлар,
Балачакларыгызны?
Исегезгә төшерәсезме кайчак
Елаганнарыгызны?
Ялантәпи йөреп аягыгызны
Канатканнарыгызны?
Усал әтәч, явыз ата казлардан
Талатканнарыгызны?

Хәтерлисезме, бал кортлары чагып,
Шешенгәннәрегезне?
Бер-берегез белән сугышып, кабат
Күрешкәннәрегезне?
Мәктәпләргә барасыгыз килмичә,
Киреләнгәнегезне?
Әти-әни кулдан тартып укырга
Китергәннәрегезне?

Рәхмәт әйтик без аларга баш иеп
Һәм дә Ватаныбызга!
Авыр еллар кичеп, ак юл салганнар
Безнең язмышыбызга!
Укыганбыз икән, бер дә юкка түгел –
Илебезгә кирәк булганга!
Бар да халкыбыз өчен эшләнгән,
Без дә тугры Аңарга!

Беләм, аңлап хәтергә төшерәсез,
Ул елларның газабын.
Чөнки күрә идегез тормышыбыз
Һаман алга барганын.
Һәммәбез тигез идек хокукка да:
Эшләгәннәр – почётта.
Бер ярлы юк иде хәтта, ә хәзер
Эшләмәүче – тәхеттә.


Сагынасыздыр, сагынырга мәҗбүр
Булабыз һаман гел-гел.
Гаделлек җитми яшәештә бик тә,
Шуңа үсенми күңел.
Очынмый хыял күккә, канатланмый,
Артта терәк нык түгел.
Максатларга ирешепләр булмаслык
Киртә куелган бүген.

Яшьләр йөри кайнап, көч-егәрен
Кая куярга белми.
Киләчәге тар аралыкка кергән,
Караңгы – берни күрми.
Ул күрми нурлар балкышы яктысын,
Дөнья бит шаулый-гөрли.
Күз алдында бары доллар төсе калка,
Шул доллар тынгы бирми.

Әйе, сагынабыз, дуслар, яшь чакларны,
Сагынмый мөмкин түгел!
Чөнки без динебезне, денебезне,
Вөҗданыбыз һәм Ватанны акчага
Алмашыр буын түгел!



Салават НИГЪМӘТОВ



Виктор ФЁДОРОВ



ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Безне бит әйбәт музыкадан бөтенләй биздереп бетерделәр. Элек ул радиодан да, телевизордан да яңгырый иде, чынлап җырлый белүче артистларның концертларына арзан бәя белән йөрергә була иде. Хәзер исә кая карама, тавышлары чамалы җырчы, өч тиенлек музыка һәм мәгънәсез сүзләр...

Л. ГАРИПОВА

әлмәт

Укучыбызның хаты Шомбай аганы бик кызыксындырды.

– Ә мин яхшы музыканы озак итеп кайда тыңларга икәнен беләм, – диде аксакалыбыз. **– Теләсә кайсы оешманың телефонын җыярга һәм җавап биргәннәрен күтәргә генә кирәк...**

Рәфкать ИБРАҺИМ

КАРАКЛЫК

Ай-яй, остарды караклар,
Урлыйлар да, талыйлар.
Карт бит инде дип тормыйлар
Әбиләрне аулыйлар.


Каракларга ирек бирсәң,
Бөлдерерләр илеңне.
Алар болай кылансалар,
Без бетәбез түгелме?..

Каракның үзе кебек үк –
Бетми торган сүзе дә.
Киредән укыгач та бит
"Карак" – каһәр сизелә.

Телефон аша да керәләр
Алар безнең кесәгә.
Бюджетта да караклык бар
Урлый торган нәрсәгә.

Күңелгә шундый уй килә
Ничек чыдый җәмгыять?..
Караклыктан ахыр заман
Житә бугай, җәмәгать...






Александр ШУЛЬПИНОВ

•••

– Без – атлар, – ди ат ишәккә, – йорт хайваннары арасында иң игелекле кавем. Без кешеләрнең хезмәтен җиңеләйтәбез, ял сәгатьләрендә тормышларын бизибез.

– Бәлки, шулайдыр да, – дип җавап бирә ишәк. – Әмма вакыт узу белән сезне машиналар кысрыклап чыгарачак һәм сезне искә генә алачаклар. Ә менә ишәкләрнең мәңге бетәсе юк.



Валерий ТАРАСЕНКО

– Мин «Тигр» һәм «Пантера»ларны шартлата идем, ә оныгым хәзер – «Леопард»ларны!

Бурычлылар армиясе

Кайчагында гаиләдәге ир-хатын мөнәсәбәтләрен «Комплиментттан – алиментка» дигән кыска җөмлә белән билгеләргә була. Гыйшык-мыйшык, ай нурында кочаклашып утырулар, аннан соң бергә яши башлаулар еш кына күңелсез тәмамлана, һәм алимент өчен аяусыз көрәш башлана. Ә бу гади нәрсә түгел – һәр ата кеше үзенең кантир түгеп эшләгән акчасын үзе теләп җан парәсе өчен корбан итәргә теләми. Моннан котылу өчен хәйләләр җитәрлек: конверттагы хезмәт хакы, рәсмиләштерми генә торакны арендага бирү, автомобильләрне ата-анаң исеменә яздыру һәм башкалар. Ләкин түләүдән качып йөрүчеләрне якасыннан эләктерүнең ысуллары да аз түгел.

Мәсәлән, Казанда элемтәгә чыкмыйча, ярты миллион бурыч җыйган бер атаны приставлар түләүсез белдерүләр сайтында ремонт буенча хезмәт күрсәтү тәкъдим иткәндә эләктергәннәр. Пристав, заказчик булып, күрешү турында сөйләшенгән. Әмма бу очрашу судта тәмамланган. Ә ир кешегә башка эш башкарырга туры килгән, өстәвенә, бушлай.

Ә икенче казанлыны закон әһелләре кулына ач тамак китереп тапшырган. Приставлар өйгә ризык китерү хезмәте аша бурычлының адресын ачыклаганнар һәм үзләре аның фатирына пицца китергәннәр. Ләкин алиментчы затлы ризыкны татып карарга өлгермәгән – башта ун тәүлек утырып чыгарга туры килгән. Бу хәл бичараны шулкадәр тетрәндергән ки, ул инде рәсми эшкә урнашып, бурычын түли башлаган.

Күргәнебезчә, алиментчы тормышы кайчагында маҗаралы триллерга охшый башлый. Ике ел элек шундый берәүне Спас районы судында никахны гамәлдән чыгару турында белешмә алырга килгәч тоткарлаганнар. Ир кеше барысын да истә тоткан шикелле – рәсми рәвештә беркайда да эшләмәгән, мәшгульлек үзәгендә учётта тормаган, «яшьлек хатасы»ннан ерак яшәгән, ләкин менә 60 мең бурычы булганын исеннән чыгарган. Документларын тикшергәндә үткәннәренең кара бите калкып чыккан. Нәтиҗәдә, намуссыз ата кирәкле кәгазьләр белән бергә ун тәүлек тә алган.

Әйтергә кирәк, түләүдән качып йөрүчеләр санына кайчагында ваемсыз аталар гына түгел, ә кайбер ханымнар да керә. Чиләбе өлкәсендә күп балалы булуына карамастан, юлдан язган бер хатын приставлардан эт оясында качып яткан. Закон кулына аны оя хуҗасы тапшырган.

Бүгенге көнгә илдә алиментлар буенча бурычлар 160 миллиард сумнан артып киткән, ә бурычлылар армиясенең саны 800 мең тәшкил итә. Аны исәпләп һәм тикшереп тору өчен бердәм алимент түләмәүчеләр реестры булдырылган. Балаларны карау өчен пособиеләр түләү һәм бурычлы ата-аналарны табу максаты белән Федераль алимент фонды оештырылу күздә тотыла. Тотылганнарга пособие суммасын, аның 50 процентын һәм ярыйсы гына штраф түләргә туры киләчәк. Бәлки, бу чаралар җавапсызлыкккка һәм бурычка баткан качып йөрүчеләргә бераз акыл өстәр?

Людмила САФИУЛЛИНА


Валентин ДУБИНИН


Виктор ФЁДОРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

Михаил ЛАРИЧЕВ





Валентин ДУБИНИН



• • •

Ир кеше аракы сатып ала. Шешәсенең башына пакет белән чикләвек беркетелгән.

– Чикләвеге ни өчен?

– Анысы, "белочка"дан котылу өчен.

• • •

– Сез өйләнгәнме?

– Аерылышкан.

– Нык аерылыштыгызмы?

– Трусикны калдырдылар...

• • •

– Кем анда эт кебек улый?

– Бу мин, әни.

– Ә-ә, синмени... Жырла, жырла, сандугачым.

• • •

Профессор студентка әйтә:

– Котлыйм! Сез әле генә, "бишле"гә испан теленнән имтихан бирдегез, ләкин без француз телен өйрәнгән идек.

– Гафу итегез инде, профессор, кичә төнлә киштәдән ялгыш икенче китапны алганмын.

• • •

Кечкенә кызы – әтисенә:

– Акырма миңа, мин синең хатының түгел!

• • •

Берәү операция ясатырга жыена. Танышы моңа киңәшләр бирә.

– Болай ит: санитарларга 100 тәңкә бирерсең, хирургка – 2000, анестезиологка – 5000.

– Син нәрсә, акылдан яздыңмы әллә? Анестезиолог берни дә эшләми бит ул. Биш мең бары тик йоклаткан өчен?! Кычкыртып талыйлар түгелме!

– Юк шул, дустым, йоклатыр өчен 100 тәңкә дә житә, ә менә калган 4900 ы– анысы уяту өчен!

• • •

– Языгыз: "Мин, ачык акылым һәм чын хәтеремдә, үземнең фатирымны бүләк итәргә телим..."

– Гафу итегез, бу дәрестән дә тоталь диктантмы?

• • •

– Нәрсә белән эшләячәк киләчәктә экологик транспорт?

– Су һәм үлән белән.

– Ничек эшли инде ул техника?

– Арбага алашаны жигәсең дә...

• • •

– Сиңа күп акча, уңышлы элемтәләр һәм олы хөрмәт телим.

– Әйе, алар минем болай да житәрлек.

– Алайса, калган көннәреңне иректә уткәрүеңне телим.



Абау!

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР БУЕНЧА

Чаллыда ике егет җитди срокка тартырлык күләмдә наркотик әзерләгәннәр. Интернеттагы "файдалы киңәшләр"дән файдаланып, алар гаражда мефедрон җитештерү буенча лаборатория эшләтеп җибәргәннәр. Башта бер килограмм наркотик ясап, дуслар аны Интернет кибете аша сатканнар. Ләкин бизнес озак чәчәк ата алмаган, оперативниклар аны җәһәт кенә япканнар. "Лаборант"ларның запасында тагын бер кило чамасы зәһәр матдә табылган.

ЯҢА ЫСУЛ

Егерме яшьлек Казан егете акча ясау ысулы уйлап чыгарган. Ул электрон сәүдә кибетендә кыйммәтле смарт-сәгатьләр һәм наушниклар сатып алган. Өендә аларны ялган товарга алыштырган һәм маркетплейска кайтарган. Үзендә калган чын гаджетларны шома егет түләүсез белдерүләр сайтында саткан. Тикшерү органнары тарафыннан өч дистәгә якын сату-алу очрагы ачыкланган, ә аферистның фатирында әйләнеш өчен әзерләнгән оригиналь һәм ялган товар үрнәкләре тапканнар.

ТҮЛӘҮ ӨЧЕН МАТДИ ЯРДӘМ

Артык зур булмаган акча түләп, хәлле генә кеше дә мохтаҗга әверелә ала икән. Республика матди ярдәм үзәге хезмәткәре Алёна В., документларда гаилә керемен киметеп күрсәтеп, еш кына шундый "фокус" ясаган. Бушлай түгел, әлбәттә – моның өчен ул "ярдәмче"ләре аша 5–10 мең сум алып барган. Бу хезмәтне кабул итүчеләр исә буш калмаганнар: 40 тан 140 мең сумга кадәр матди ярдәм алганнар. Ә менә алар өчен яхшы гамәл кылучы төп башына утырып калган. 600 мең сум зыян китергән өчен аңа берничә ел уңайлыклары аз булган торакта яшәргә туры килмәгәе.

ИСЕРЕК БИСТӘ

Иҗтимагый тыңлаулар барышында Түбән Кама хакимияте кызыклы тәкъдим алган. Ул, автор фикеренчә, "исерек бистә" булдыру ярдәмендә халыкны айнытуда ярдәм итәчәк. Бу бистәдә яшәүчеләр дәүләт медицинасы, полиция, мәгариф, мәдәният хезмәтләреннән мәхрүм ителергә тиеш. Бу урында алкоголь сәүдәсе рөхсәт ителәчәк һәм бөтен хәмер бизнесы шунда сөреләчәк. Бу фикернең авторы аракы-шәраб заводларының хуҗалары үзләренең яклаучы-лоббистлары белән бергә шунда яшәргә тиеш, дип саный. Шулай итеп, нефтехимиклар каласында бары тик аек кешеләр генә калачак икән.





Александр БРЮХАНОВ

Күндерә белү кирәк

Кичен Тансыков фатирында телефон шалтырады. Ул телевизор караудан арынып, трубканы алды. "Әлү" дигәнне көтмичә үк, ягымлы тавыш сөйли башлады:

– Сезне җиһазлар салоны "Буратино" борчый, тәкъдимебез – яхшы товарлар кайтты, шуны хәбәр итү.

– Рәхмәт, миңа бернәрсә кирәкми, минем бар нәрсәм дә җитешле, – дип бүлдерде аны Тансыков.

Кәнәфиеннән торып кузгалуы булды, яңадан телефон шалтыравы. Тансыков трубканы күтәрде... Һаман шул ук тавыш кебек тоелды аңа бу юлы да:

– Сезгә көнкүреш электр приборлары тәкъдим итәргә телибез: лампалар, люстралар, бралар...

– Миңа алар да кирәкми, – дип тавышын кискенләштерде дә трубкасын куйды.

Ләкин берничә секундтан соң телефон яңадан тавыш бирде:

– Без сезгә сигез төрле үзебезгә пешергән пиццалар тәкъдим итәбез. Телегезне йотарлык, бармакларыгызны яларлык...

– Үзегез ялагыз бармакларыгызны, туйдым мин сездән, гарык, – дип кычкырырга ук тотынды Тансыков, ләкин җавапка телефон гудогын гына ишетте...

– Әлү? – дигән пышылдау тавышы белән сөйли башлады бер хатын-кыз, өч секунд та үтмәгәндер... Сезне күңел тынычлыгы үзәге борчый... Ашыгыч психик ярдәм күрсәтәбез...

– Сез мине вакытыннан алда гүргә кертәсез!!! – дип кычкырды Тансыков, трубкасын ташлап...

Шундук:

– Сезне ритуал ярдәм күрсәтү бюросы сәламли, – дигән сүзләр яңгырап калды Тюшкинның колагында.

– Ай, миңа начар, – дип ухылдады ул.

Ун минут та үтмәгәндер, ишектә звонок тавышы чыңлый башлады. Бусагада ак халатлы кешеләр пәйда булды.

– Сезгә дәваланып алу өчен сырхауханәгә ятарга тәкъдим итәбез.

Акылын җуя башлаганда, Тансыков килүчеләрнең берсеннән мондый сүзләр ишетеп калды:

– Реклама иң кирәкле нәрсә – ул максатны туплап бирә белү, берсе булмаса, икенчесе клиентны барыбер күндерә.

Рөстәм ЗАРИПОВ

БЕЗ

Акчалар эшләргә тиеш,
Шулай ди экономист...
Аларны җигеп күп илләр
Череп баеп ята ич...
Безнекеләр эш яратмый,
Уртак булганга холык...
Яшиләр юка кесәдән
Киң кесәгә омтылып...
Без дә кесәгә салынган,
Кемнәрдер тарафыннан,
Кем өч тиен, кем биш тиен,
Кем сумнар арасында...

• • •

Бар да булыр, вакыты ул түгел,
Көне житәр, килер ул вакыт...
Ә ул килми, бары китә генә...
Китә генә... Булмый туктатып...

КЫЗЫКСЫНУ

Нинди урында утыра!
Текә күренә тыштан!
Бу куштанны күтәрергә
Кайсы куштаны кушкан?

1 СЕНТЯБРЬ МАТАВЫГЫ

Чыгымнар җыелды бирнәлек,
Югыйсә кияүгә бирмәдек,
Кызыбыз юл тотты мәктәпкә,
Беренче сыйныфка, әлбәттә...



Сергей КОКАРЕВ

Евгений БУГРОВ

Бизнесвумен

Мәрьям ханым, төзелеш компаниясендә баш бухгалтер булып эшләгәндә бу турыда соңгы биш ел буе хыялланды. Ул күптән уйлана иде инде: пенсиягә чыккач, үземнең бизнесымны ачам дип. Башта байтак акча җыярмын, аннан соң... Аннан соң нәрсә буласын ул белми иде, ләкин подъезд кырыендагы эскәмиядә утыручы әбиләр аны башкача исемлиләр иде – "бизнесвумен" дип.

Менә ул көн килеп тә җитте. Эшне бик озакка сузмыйча, түләүсез реклама сайтына белдерү язып җибәрде: "Өч бүлмәле фатирымны байтак вакытка биреп торам". Шул ук сайттан үзенә бер бүлмә дә юнәтеп, атна үтүгә үк фатирдан килгән керем чишмә кебек кенә түгел, мул сулы елга кебек ага башлады моңа. Мәрьям ханым әлеге уңышка гына канәгать булмыйча, үз бүлмәсенә дә кешеләр кертеп, бакчасындагы иске өенә күчте. Эшләр җайга китеп, ул бу бакчасына да кешеләр табып, Сочидагы сердәшенә китеп барды.

Күрешеп, анда озак яшәргә туры килмәде: сердәшенең кызы Вологдада яши икән, авырып киткән, һәм җан дусты аны коткарырга шунда очкан. Ә Мәрьям ханым ни эшли? Ул инде хәзер яшәү өчен кулай фатирларны арендага биреп тору буенча остарган кеше буларак, шундук сердәшенең ике бүлмәле торагын ял итәргә килүчеләргә бирә. Ә үзе кладовкадан иске студент палаткасы табып, диңгез кырыендагы комлыкка күчә. Янәмәсе, "кыргый" ял итүче. Шуннан соң башына мондый уй килә: нигә әле бу палатканы да көне буена биреп торып, үзенә кояш астында кызынып, диңгез ярында гына йөрмәскә. Мәрьям ханым уңышлы бизнесы белән генә яши: фатирга керүчеләрдән кесәсенә түләүләр ага тора, матур киләчәк турында хыяллана.

Әллә кояш бик каты кыздыра, әллә зур уңышлар башын әйләндерә, берзаман моны кызу суга, һәм ул хастаханәгә эләгә.


Бу ята торган караватны да берәр мохтаҗ кешегә биреп торып булмас микән дигән уй борчый башлый аны аңына килү белән. Ләкин "кояш сугу" бик каты икәнен аңлап, әлеге уйдан шундук кире кайта.

Тагын кайдан акча юнәтеп буласын безнең түләүсез медицина шулай ук уйлый белә, һәм бу сорауны Мәрьям ханымга күчереп куя. Шулай итеп, реаниматологлар, кардиологлар, неврологлар һәм башка табиблар агымдагы кварталга буласы премия күләмен алдан чутлап, куанып утыралар.

Инде ахырда, бар нәрсә дә үз җаена кергәч, һәм безнең бизнесвумен үзенең өч бүлмәсенә кайтып егылгач, аның кереме "комга сеңгән су" кебек кенә икәнлеге беленә. Ә өч көннән соң аның стратегик планы, гомумән, зыянлы икәнлеге ачыклана – Мәрьям ханымга суд приставлары килеп җитә. Карар катгый: "Торак урыннарын килешүләрсез һәм салым түләмичә биреп, акча үзләштергән өчен..." Юк, алда тагын нәрсәләр булганын язып тору килешмәс... Барысын да чутлап бетергәч әйтермен мин сезгә.







ТИШЕК КӨПЧӘК

БАШСЫЗ «ҖАЙДАК»ЛАР


Илдәге ике гадәти бәлагә – җүләрләр һәм юлларга тагын берсе өстәлде бугай. Ул да булса – самокатчылар. Юл вакыйгалары турындагы яңалыкларда шул башсыз токым вәкилләре искә алынмаган көн сирәктер. Йә тыныч кына барган әбекәйне бәреп егалар, йә трассага атылып чыгып авария ясыйлар, йә бер-берсе белән юл бүлешә алмыйлар. Интернет ике көпчәкле камикадзелар катнашы белән видеосюжетлар һәм ачулы комментарийлар белән тулы: бу хәл озак дәвам итәчәкме? Мәсәлән, чираттагы бәрелүдә опера җырчысы Любовь Казарновская зыян күргән. Ертык чалбарлы, җәрәхәтләнгән тезләре белән ул камера каршында Мәскәү урамнарын җәяүлеләрне имгәтүче акылдан язган, күзләре акны-караны күрмәүче самокатчылардан арындыруны үтенде.

Ә Казан урамнарында хәлләр ничегрәк соң? Бездә, кем әйтмешли, торбасы да тәбәнәгрәк, төтене дә сыеграк булса да, проблемалар шул ук. Узган ел эчендә республика башкаласында «шәхси хәрәкәт чаралары» катнашы белән 34 юл вакыйгасы булган. Анда 35 кеше төрле дәрәҗәдәге җәрәхәтләр алган, аларның 12 се – балалар. Быел да зыянсыз булмас дип, зур өметләр баглап булмый – күңелсез вакыйгалар дәвам итә, инде корбаннар да бар.

Самокатчыларның тыелгысыз «җен туен» чикләргә теләмиләр дисәк, бу тормышка туры килмәс иде. Татарстанда, әйтергә кирәк, җәяүлеләр өчен дә, җилдертергә яратучылар өчен дә уңайлыклар тудырырга тырышалар. Моның өчен махсус юллар булдыралар, төрле чикләүләр кертәләр. 2022 елда, мәсәлән, самокатлар өчен шәһәрдә йөрүнең максималь тизлеген сәгатенә 25 километрдан 20 гә кадәр киметтеләр. Шулай ук җавапсыз тизлек сөючеләргә югарыдан зур штрафлар, самокат йөртүчеләр өчен идарә итү таныклыклары кертү, ике көпчәкле бизнес хуҗалары өстеннән контрольне көчәйтү, аны тулысынча тыю һ. б. тәкъдимнәр яңгырый.

Әмма, законлылык тирәсендәге шау-шуга карамастан, урамнарыбызны басып алган самокат җене үз кагыйдәләре буенча, төгәлрәк әйтсәк, бернинди кагыйдәсез җилдерә бирә. Аны законлы һәм хәвефсез кысаларга кертеп булырмы – моны вакыт күрсәтер. Ә хәзергә Казанда Пушкин һәм Дзержинский урамнары чатындагы «зебра»да джип автомобиле самокатка килеп бәрелгән. Тизлек сөюче егет әллә ни зыян күрмәгән, ә менә аның «елгыр аты» турында алай дип әйтеп булмый.

Артур ВАЛЕЕВ



Вячеслав ШИЛОВ



Николай ВОРОНЦОВ



•••

Табиб авыруны җентекләп караганнан соң әйтеп куя:

– Сезгә үзегезне бик сакларга кирәк. Эчмәскә, тартмаска, артык дулкынланмаска.

– Хатынымны кочакларга ярыймы соң?

– Иң соңгы очракта гына. Анда да тик үз хатыныңны.





Айдар ФАРТОВ

Сайлану

Табын тулы төрле нигъмәтләр алдында үземне дөньядагы иң бәхетле кияү итеп сиздем. Кәләшемә утыз тулган, ә үземә утыз алты. Шуңа күрә безнең ярәшүебез уйланып эшләнгән нәтиҗә һәм дә кире уйлау мөмкин нәрсә түгел.

– Бердәм медицина династиясе өчен тост тәкъдим итәм! – дип башлады сүзен булачак хатынымның әтисе. – Безнең киявебез талантлы табиблар гаиләсеннән. Шулай бит?

– Әйе. Әнием – бүлек мөдире. Аның киңәше белән мин дөрес һөнәр үзләштердем.

Инде алкоголь үзенекен итте – булачак кайнатаны аклану басты.

– Кызымның тормыш иптәшен озак таба алмавына үзем гаепле. Теш табибы булмаган булса, күптән кияүгә чыккан булыр иде. Әйе!

Аңламаган кыяфәт чыгарып, кәләшемә карап куйдым. Ул иңнәрен сикертеп куйды. Шунда аның әнисе телгә килде.

– Без аны байтак егетләр белән таныштырып карадык... Бик әйбәтләре дә бар иде, акыллылары, ләкин алар аңа ошамады.

– Ни өчен? – дип кызыксындым мин, кәләшемә карап.

– Иң беренче йөргәне Илдар – энциклопедик дәрәҗәле белгеч, белмәгән нәрсәсе юк иде. Аннан соң Ринат – килеш-килбәткә бик тә яхшы. Камал театры артисты диярсең. Аны Алмаз алыштырды, әтисе – район масштабындагы түрә...

– И-и?! – дип көлемсерәп куйдым мин.

Кәләшем моңсу гына ухылдап алды да:

– Илдарның өске аңкавында ике теше юк иде – "егерме беренче" һәм "егерме икенче"се. Ринатның тешләре "әпипә"гә биегән төсле иде. Ә Алмазының тешләре аңкавы белән кыйшайган иде.

– Ә Фәниснеке? – диде кайнана.

– Фу! Аның пародонтит, – дип җирәнгеч төс чагылды кәләш йөзендә. – Тиз ара дәваларга кирәк. Ташларын алырга. Мин аңа моны йөзенә бәреп әйттем.

Чираттагы әфлисунын ашап, кыз муенын кашып алды. Аннан соң аның бармаклары чигәсенә һәм маңгаена менде. Сиздерми генә үземнең булачак хатыныма карап, уйланып калдым...

– Ниһаять үзеңә тиң яр таптың, улым, инде өйләнәсең дә! – дип каршылады мине әнием, ишек бусагасыннан атлап керүгә үк. – Ничек үтте очрашу? Кайчан туй ясыйсыз?

– Мин кире уйладым әле, әни! Ул үзенә тиңнәрне тешләренә карап сайлый икән, чирләре буенча. Стоматология белән җенләнеп беткән...

Әни, авызын ачып, аптырап калды.

– Синең бит тешләрең бик әйбәт! Инде... монысы бит сигезенче кызың, барысының да гаебен таптың...

– Шуннан нәрсә?! Тугызынчысын табармын. Анысы белән миңа әйбәтрәк булачагы көн кебек ачык.

– Бусының тагын нәрсәсе җитешмәгән? – дип төпченергә тотынды әни.

– Минем уйлавымча, ул кызда дерматит, ә бәлки чесотка дадыр, ул гел кашынып утырды. Чабырып чыккан җирләре дә бар иде.

– Бәлки ул аллергиядер яки кычыткан бизгәгедер? – дигән төзәтмә кертте әни. – Ныгытып тикшерергә кирәк. Теленә игътибар иттеңме, улым? Иренә? Герпесмы әллә?

– Өстәвенә, әни, паника күтәрәсем килмәде, кандидоз да юк микән, молочница һәм микоплазмоз – боларны бит берәү дә инкарь итми.

– Тынычлан, улым! – акыллы әнием башымнан сыйпап алды. – Интектермә кәләшне, үзеңне дә. Тиз арада кирәкле анализлар алырбыз. Алып кил син аны безнең тире-тән венерология диспансерына...



Хәмид ВӘЛИДИ

Бер тотынгач...


Базарлардан озак эзләп аргач,
Табалмагач, хәтта, алтынга,
Кәҗә мөгезеннән үкчә куеп,
Туфли тегеп бирдем хатынга.
Ачылгандай булды "Күк капусы"
Шул кичендә миңа, җегетләр,
Гомер иткән ярым бер мактады:
– Беркайда юк, синең кебекләр.
Атылды да килеп кочагыма,
Үбә-коча гафу үтенде.
– Кичер мине, юньсез диеп йөрдем,
Зинһар, җаныем, гафу ит инде.
Ә, мин көләм, миңа сөенеч бары,
Кеше куандыру – шәп нәрсә!
Сакалыннан керфек ясыйм әле,
Әгәр бик тә үтенеп сораса.
Бер тотынгач үтим инде аны,
Тик хәерле булсын ахыры.
Кәҗә дә җәл – ата кәҗә, мескен,
Гарьлегеннән яман бакырыр.
Түзәр әле, ир-затыннан ич ул,
Ирләр хәлен аңлар берсүзсез.
Туфлисез яшәп булмый ласа,
Яшәп булган кебек... мөгезсез.



Валентин ДУБИНИН



Виталий ПОДВИЦКИЙ





Абау!

БЛАТЛЫ МУЗЕЙ

Суд элеккеге Мәдәният министры урынбасары Ольга Яриловань Пушкин картасы белән алдаган өчен 7 елга хөкем иткән. Рәсми зат льготалы программага Мәскәүдәге «Иң югары тундырма музееы» кертергә булышкан. Аның исемендә «музей» сүзенә карамастан, бу шәхси оешманың экспонатлары һәм тиешле статусы булмаган. «Москва-Сити» манараларының берсендә кечкенә туңдырма җитештерү линиясе урнашкан, тик билет бәясе 1650 сум. Бу искиткеч туңдырманың нечкәлекләрен белүче үз бүлегенә 125 миллион сум зыян китергән.

КОЛЛАР БЕЛӘН ЭШ ИТКӘН

Балашиха пенсионеры акча теләнү белән шөгыльләнгән. «Эшләү» кыенлашкач, хатын күрше дәүләтнең алты гражданын үз колларына әйләндергән. Яңа коллар хуҗасы документларын һәм телефон номерларын алган, физик һәм психологик көч кулланган. Һәр иртә хуҗабикә колларны үз урыннарына илткән. Көндез җыелган акчаны җыеп алган. Эшлекле пенсионер хәзер үзе ирегеннән мәхрүм калырга мөмкин.


КАРАК КАРАКНЫКЫН

Социаль челтәрләрнең берсендә блогерлар арасында авторлык хокуклары белән катлаулы проблема килеп чыккан. Мәскәүле риэлтор «Ипотека түләгәч нәрсә эшләргә» дигән видео төшергән һәм аны үз битенә урнаштырган. Берникадәр вакыттан соң ул хезмәттәшендә шундый ук ролик тапкан, судка биргән һәм җиңгән. Бераз соңрак Санкт-Петербург шәһәрендәге риэлтор да кушылган. Алар судка кадәр җиде ай алдан шундый ук видео төшергәннәр. Сенсацион хәбәрнең дәвам булачагы әлегә билгеле түгел, Санкт-Петербург кешеләре судка барыргамы, аңларгамы, кичерергәме икәнен хәл итәләр.

ЯЛГАН АГЕНТСТВО

Түбән Новгородта «Mary Way» модельлек агентлыгы кызлар җыйган. Кастингка килгән һәр кызны чибәрлегендә ышандырганнар, Миланда һәм Парижда подиум вәгъдә иткәннәр. Кызлар контрактка һәм аңа өстәмә килешүгә кул куйганнар. Ләкин җентекләп тикшергәннән соң бу 50–150 мең сум күләмендә кредит алу өчен документлар булган. Ике дистәгә якын уңышсыз модель полициягә мөрәҗәгать иткән.




Игорь КИЙКО



Вячеслав ШИЛОВ

ТҮТӘЛ ӨСТЕНДӘ ШАЯРТУЛАР

• Элек әни мине генә ярата дип уйлый идем, ә соңрак аның бакчада үскән помидорларга ничек караганын күрдем.

• Африкадагы ачлыкны җиңүнең иң үтемле ысулы – мохтаҗларга әти-әни бакчасында үскән кабакларны җибәрү.

• Тырмага басарга була, сәнәккә кадалырга мөмкин, бары тик көрәк кенә беркайчан да зыян китермәс.

• Бакчада фитнес белән шөгыльләнү – иртән иелдең, кичен тураеп бастың.

• Бакчадагы бәдрәфнең тәрәзәсен йөрәк формасында кисү өчен мәхәббәттән ни дәрәҗәдә гайрәтең чигәргә тиеш?!

• Иске әйберләрнең гадәти юлы: кладовка–балкон–дача.


Александр ШУЛЬПИНОВ



Валентин ДУБИНИН

Рәис ГАЙНЕТДИНОВ

“ХРУЩЕВ” БОЗАУЛАГАН!

Никита Хрущев ил белән идарә иткән елларда сөт, ит җитештерү өлкәсендә Әмрикәне куып җитеп, узып китү нияте белән, шәһәрләр, посёлоклар хуҗалыкларында асраган сыерларны хуҗаларыннан елата-елата мәҗбүри рәвештә алып колхоз, совхозларга тараттылар. Чөнки алар, колхоз сыерларыннан аермалы буларак, күп сөт бирә торган нәселләләр иде.

Менә шундый бер дистәләп сыерны безнең авыл фермасына да кайтардылар. Иптәш Хрущев инициативасы белән кайтарылган булганга аларның берсенә “Хрущев” кушаматы биргәннәр.

Салкын кыш көннәренең берендә, таң йокысының иң тәмле вакытында, ферма каравылчысы, шул сыерны караучы, савучы апаның өенә атылып керү (ул чакларда авыл җирендә ишекләрне бикләү гадәте юк иде) белән:


– Фәлән апа, ни җаның белән шушы вакытта йоклап ятасың, синең “Хрущев”ың бозаулады бит! – дигән сөенечле хәбәрен җиткерә.

ШӘМГУН

РӘИС ГАЙНЕТДИНОВ ЯЗМАСЫНА ИЯРЕП...


Хрущёв заманнары безгә дә тәтеде. Хәтердә калганча, ул елларның хәсрәтләрен без дә татыдык. Шулай да, нығытыбрак уйласаң, балачак һәрвакыт күңелле, матур, шатлыклы вакыйгалары белән күңелгә кереп кала. Хәзерге тормыш бәяләмәсеннән карасаң, безнең үсмер чорыбыз гел хәерчелектә үткән икән. Кара инде, чалбар төшеп китмәсен өчен юкә бау белән буып куелган, яланаяк йөрибез, носкиның нәрсә икәнен белмибез, ишеткәнебез дә юк. Галуш киеп йөргән кеше инде бик культурный саналгандыр... Һәммәбездә – чабата. Тамак ачса күпләребез капка төпләрендә черек бәрәңгедән пешерелгән көлчә ашап утыра. Ипигә май ягып ашау төшкә дә керми. Хуҗалыкта ни эшлибезме? Ишегалды себерәбез, чүп түгәбез, бакчада бәрәңге – аны карыйбыз. Колхоз атларын көтәбез, ә кызлар үзләре чүпрәктән ясалган курчак белән уйныйлар, әниләренә булышкан булып су ташыйлар, идән юалар. Без – малайлар, көтү кайтканнан соң өйгә кермичә саташып качкан сарыкларны авыл буйлап эзлибез. Күп иде инде безгә йөкләнгән мәшәкатьләр. Уйнарга да вакыт калгалый иде. Үзебез генә белә торган уеннар да байтак. Ул чакларда урам буйлап колхозның “полуторка”сы узып китсә, аның артыннан чабабыз – безгә ул да рәхәтлек бирә. Аннан соң безнең авылда Гани абзый гына кабыза-сүндерә белә торган КДП тракторы бар иде. Ул тракторга, пенсиягә чыгып, фермада савымчыларга электр лампочкасы кабызу вазыйфасы йөкләтелгән. Гани аның баш хәрефләрен безгә болай итеп аңлата: “Какой дурак придумал” дип. Аңлап бетермәсәк тә, көлә идек инде шаркылдап.

Ә бит, бер уйласаң, сугыштан соңгы елларда авыл хуҗалыгындагы андый тракторлар, сирәк булсалар да, киләчәк үсешкә нык этәргеч ясаганнар.



– Алга таба да улыгызны шулай тәрбияләсәгез, атагызны чакыртырга туры киләчәк!

Иван ХАНТИМЕРОВ, 1966 ел.



Үлчәү алынды.

Герман ОГОРОДНИКОВ, 1966 ел.



• • •

Бер ир, күпмедер вакыт узгач, сатып алган бензопычкасы белән зарланып, кабат кибеткә килә:

– Инструкциясендә болай дип язылган, "көненә 5 кубометр утын кисәргә була, ә мин нихәтле тырышсам да, 3 тән артмый".

Сатучы:

– Карыйк әле.

Һәм бензопычкыны кабызып җибәрә.

Ир:

– Карале! Ничек алай гөжләп эшли башлады әле ул?

• • •

Сырхауханәгә агуланган карчыкны алып киләләр. Ашказанын юдыралар, капельница куялар. Янына доктор килә:

– Сезне бит инде үткән атнада бер китергәннәр иде гөмбә белән агулангач. Бу юлы нәрсә булды?

– Соң, җаным, шуларны ашап бетергән идем!

• • •

– Бизнеста шундый уңышка ничек ирештегез?

– Аңлыйсызмы, акчада түгел эш, социаль бәхет тә зур роль уйнамый, тормыштагы уңышлар да этәргеч ясамый, иң әһәмиятлесе – эшеңә тулысынча бирелү, предприятиеңә, әле бигүк акча китермәсә дә, бөтен көчеңне биреп эшләү. Бары тик күмәк көчнең файдасы булуына инану!

– Менә шул хыял сезне уңышка китердеме?

– Юк, мин аның шулай булачагын хезмәткәрләремә сеңдердем.

• • •

Хатын-кыз белән бәхәсләшү – ул шуңа тиң лицензион килешү укыгандай. Барыбер ахырдан бернәрсә дә аңламый башлыйсың һәм бирешәсең: "Мин риза", дип...

• • •

Табиб – авыруга:

– Хәзер сезнең авырлыгыгыз нинди?

– Җитмеш.

– Ә иң нык авыр чагыгыз?

– Сиксән.

– Ә иң җиңел вакытыгыз?

– Өч тә өч йөз грамм.

• • •

– Чибәркәй, икенче тукталышта чыгасызмы?

– Миңа алай карамагыз, сезнең белән танышырга уйламыйм. Мин икенче тукталышта чыгарга гына телим.

– Юк инде. Таныштык бит. Чыгабыз. Икенче тукталыш бик урынлы – ЗАГС. Паспортың үзең беләнме?

Вячеслав ШИЛОВ рәсемнәре











ҖАЙЛЫ ЫСУЛ ТАПКАННАР

Кадерле "Чаян"! Котырган эткә җиде чакрым ара үтү кыен түгел. Мөгаен, нәкъ менә шушы мәкальгә туры китереп уйланылган эш булгандыр җитәкчеләрнең бу гамәле – безнең авыл кырыеннан үтүче трассаны үзгәртеп салгач, авыл кешеләре өчен көтелмәгән җиргә бүлә торган отбойник тергезделәр. Мәсәлән, Рус Акташында ул Әлмәт–Зәй трассасы белән икегә бүленгән. Шул бистәнең үзәгенә эләгү өчен анда мәктәп һәм балалар бакчасы, ике километр – бер якка һәм шуның хәтле кирегә килергә кирәк. Ә күрше Югары Акташта трасса аркасында шулай йөрү – 8 километрга җыела. Менә интегеп җан асрыйбыз. Шул сәбәпле, инде байтак фаҗигаләр дә булды. Ләкин камералар һәм светофорлар яки өстәмә юл кагыйдәләрен үтәү өчен куелырга тиешле юл күрсәткечләре бөтенләй уйланмаган. Җайлы гына ысул тапканнар. Әмма безнең өчен түгел.

Рус Акташы, Югары Акташ халкы.

Әлмәт р-ны

ТЕГЕЛӘЙ ЯРАМЫЙ – БОЛАЙ ЯРЫЙ

Хөрмәтле редакция! Чүпне никадәр тыгызлап тутырма, аны барыбер чыгарып түгәргә туры килә. Без, Вознесение бистәсендә яшәүчеләр, бу мәсьәләне ишетеп кенә түгел, үз микъелыбызда беләбез, ә менә хакимияттәгеләр һәм чүплеккә җаваплы оператор, күрәсең, белми. Инде биш ел буе без көнкүреш калдыкларын читкә чыгару белән интегәбез. Махсус чүп җыю урыннары булдыру каралмаган. Төрле җирләрдә барлыкка килгәли алар, ләкин кайчан бушатылырга тиешлекләре билгесез. Шуңа күрә чыгарып ташланган артык калдыклар урам этләренең яраткан урынына әйләнә. Янәшәдә урман булуына карамастан, саф һава чүплектән аңкыган ис белән буталып, укшыта башлый.

Без инде бу турыда Экология министрлыгына да язып карадык, администрациядәгеләргә дә, депутатларга да – чарасын күрергә теләүчеләр күренмәде. Акланыр өчен бер сәбәпләре бар, безнең яшәгән җиребез "яшел зона" икән. Шуңа күрә берничә дә бетон корылмалары, коймалар куярга ярамый икән. Ә менә бистәбезне чүп зонасына әйләндерергә – анысы рәхәтләнеп...

Вознесение бистәсендә яшәүчеләр.

КАЗАН

Сергей КОКАРЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Ринат АБЗАЛОВ

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Дистанционка

Кичке аштан соң хатыны сүз башлады:

– Карале, сөеклем, мин дистанционкага күчәргә булдым. Нәрсә әйтерсең?

– Алай эшләп буламыни? – дип җавап кайтарды ире.

– Ничек кенә була! Менә үзең уйлап кара: сине эшкә озатам, балаларны ашатып-эчертеп мәктәпкә җибәрәм. Аннары өй эшләрен үтим. Буш арада үз эшемне дә эшләргә өлгерәм.

– Белмим шул ни әйтергә дә. Бер карасаң, яхшы инде, син һәрвакыт өйдә, балалар күз алдында... Бер нәрсә генә борчый: син эш урыныннан китә алмый торган җирдә эшлисең бит. Анысы ничек булыр?

– Һе, кайгырма. Телефон нәрсәгә? Сораулары булса, аңлатырмын. Эшләрләр.

Таң атты. Хатыны торып иртәнге ризык әзерли башлады. Коймак, чәйләр әзерләп, ирен, аннары балаларны мәктәпкә озатып җибәрде.

Бераз вакыты булгач, подъезд янындагы эскәмиягә чыгып утырды.

– Нәрсә, күрше, эшләмисеңме әллә? – дип сорады күрше әби.

– Эшлим. Дистанционно.

– Менә-менә. Хәзер барысы да дистанционно эшли башлады шул, – дип сүзгә кушылды тагын бер күршесе. – Люстраны алыштырырга дип шалтыраткан идем электрик чакыртып. Ул да хәзер дистанционно эшли икән. Телефоннан гына аңлатып маташты. Аптырап беттем. Үзем алыштырдым шул люстраны. Ә акчасын аларга түләргә кирәк. Бу дөрес хәл буламы?

Эшенә керешергә дип өенә кергәч, ванна бүлмәсендәге кран ватылганын күреп алды. ЖЭУга шалтыратырга туры килде.

– Исәнмесез, безгә сантехникны җибәрмәссезме икән? Краннан туктамыйча су ага. Астагы күршеләргә су үтмәсен дип кайгырып шалтыратуым.

– Менә сезгә телефон номеры, шуның буенча шалтыратыгыз.

Ханым шалтырата-шалтырата интегеп бетте. Ниһаять җавап бирделәр.

– Ни эшлисез сез анда? Минем краннан су ага, ә сезгә әләгеп булмый!

– Без хәзер дистанционно эшлибез. Шуңа күрә телефоннан өйрәтәбез.

– Түләү ничек?

– Шулай ук, безнең прейскурант бар. ЖЭУга барып түлисез соңыннан, банк картасы белән туры үзебезгә җибәрсәгез дә була.

Сантехник өйрәткәннәрне үтәп, хатын кранны үзе төзәтте.

Икенче көнне үк ул эшкә җыена башлады.

– Син кая барасың иртә таңнан? – дип сорады ире.

– Дистанционка бик җайлы түгел икән. Эшкә җыенам. Үз эшемне кешегә кушмыйча, үзем эшләвем хәерлерәк.

Алмаз ХӘМЗИН

БУТАЛУЛАР

Минем филармониядә эшләгән чагым. Ләкин әлеге кызык хәлгә катнашым юк. Ә менә артистларының бу кызык хәлгә тап булуларына хәбәрдар. Шулай бервакыт Себердәге Сургуттанмы шунда, Уренгойданмы – аны-сын төгәл белмим, җырчы Илсур Сафинны сорап үтенеч килә – ниндидер бай татар эшмәкәренең хатыны юбилеенда җырламас микән дип. Китә егет шунда, тавыш бар, килеш-килбәт яхшы, җырлары күп, бер сүз белән әйткәндә – популяр. Барып төшә: хуҗаларның күзе – шар... Алар чакырган җырчы түгел икән бит бу. Нишләп килгән бу? Исемен сорыйлар, әйтә:

– Илсур Сафин!

– Җырчымы сез?

– Әйе.

Мәҗлесне башларга кирәк, уйлыйлар, җырчы булгач, әйдә, җырласын инде дигән фикергә киләләр. Алар чакырган артист булмаса да, бик күркәм күренә түгелме соң монысы да...

Җырлап җибәрә, мин сиңа әйтим, Илсур, урысчалап та, татарчалап та. Кунакларның йөзендә нур! Алкышлар! Афәрин! Ур-ра!

Шулай итеп, Илсаф (ул да Илсур Сафин) урынына ялгышып барган икенче Илсур Сафин кунакларны ду китереп, һушын алып кайта. Мөгаен, әле хәзер дә белми торгандыр үзенең бу ялгышын... Хәер, анысы мөһим түгел, ә менә кесә тутырып баеп кайтуы көләч, канәгать кыяфәтендә бик ачык чагыла иде.

БУТАЛУ

Миңа бик озак еллар буе дустым Разил Вәлиевны депутат итеп йөрергә насыйп булды, ягъни кандидатлыктан чын депутат ясап. Мин бу вазыйфаны бик тә теләп башкардым, ник дисәгез, депутатка һәрвакыт халык ышанычын акларга дигән зур йөкләмә бирелә, һәм ул бу бурычын намус белән үтәп барды, алты чакырылышта да. Андый вәгъдәле депутат-дустыңны ничек якламыйсың? Мин үзем дә гаделлекне бик яратам, аның да эшчәнлеге шуңа багышланган һәм шуңа корылган иде.

Депутатлыкка кандидат итеп тәкъдим ителгәч, Разил миңа мөрәҗәгать итә: "Әйдә, синең белән икәү тотынсак ерып чыгачакбыз", – ди. Һәм эш башлана. Минем иңдә – баян, күңелдә – җыр, юмор-сатира, Разилдә – тел! Һәр авыл клубында, мәктәп-детсадында, шәһәрендә – шулай, ару-талуны, көнне-төнне белми, базары-чурты, паркы, фермасы, китапханәсе, ашханәсе, мәчете дигәндәй, безнең ихтыярда. Башта концерт куябыз, аннан соң халыкка аңлату эшләре, хәлләрен сораштыру, нинди гозерләре бар, аларны исәпкә алу, кандидатка үтенеч-зарларын белдерү һәм үтәү. Үтәү дигәннән – Разил шуларны үтәп барды бит, ничек кодрәте җиткән! Шунысын да исәпкә алу кирәктер: бер төбәктән дүрт мәртәбә тәкъдим ителгән бердәнбер кандидат кеше ул. Бүтән андыйны мин белмим – димәк, сайлаучыга ул ошаган, димәк, гозерләре үтәлгән. Шундый депутат ясаганыма мин күкрәк кагып йөрдем һәм хәзер дә горурланам. Тик шунысына бигрәк тә игътибар итәргә кирәктер: сайлау көне җиткәч, халык һәрвакыт сорый иде: "Кайсыгызны сайлыбыз соң без, Синеме, Разилнеме?" – дип. Бутыйлар...

БУТАЛУЛАР

Берзаман үземне дә башкалар белән бутау күңелгә бик хуш килгән иде. Моны күркәм язучыбыз Ркаил Зәйдулла сөйләде:

– Элеккеге Ленин мемориалында бик тә шәп концерт бара, – дип башлады ул кереш сүзен. – Без, Марсель Галиев белән, бераз соңгарак калып, буфеттан менеп киләбез. Итагатьлек саклап, залга керергә, сәхнәдәге җырчының җырлап бетерүен көтеп, тамашачы кул чаба башласа, эчкә үтәргә мөмкинлек туа бит. Көтеп торабыз. Күрәсең, сәхнәдә Алмаз Хәмзин җырлый – таныш тавыш. Марсель әйтә: "Тавышы да әйбәт әйбәтен, ләкин нәрсәдер җитми...

Шул вакыт, пауза ясалмыйча, Хәмзин артыннан ук Ренат Ибраһимов җыр сузып җибәрде:

"Нигә күк көн саен..."

Марсель: "Менә... менә, ичмасам, җырчы! Уровень башка!.."

Ул, кәефләнеп, җыр тәмам булганчы Ибраһимовның мәкаменә хисләнде. "Яхшы җыр тиз бетә шул ул! – дигән була. – Хәмзингә әле бу дәрәҗәгә җитәргә бик ерак, у-ху-у!"

Алкышлар башланырга өлгермәде, Илһам Шакиров сәхнәгә чыкты, күрәмсең:

"Бакчалардан былбыл качса,

Көзләр тисә алмагачка..." – Марсель, тагын бөек хискә күмелеп, баш бармагын күккә төртте.

"Менә монысы инде миннән комментарий сорамый, даһиларның даһие!" – диде дә, тере Бөекне сәхнәдә күреп каласы килеп залга керде. Мин дә аның артыннан иярдем.

Карасак, сәхнәдә Илһам Шакиров һәм Ренат Ибраһимов булып җырлап торучы Алмаз Хәмзин үзе икән бит!





ЧАЯН
САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 6 (1943) июнь 2024

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.06.2024 ел.
Тираж – 2094 Заказ А-1209
Редакциянең адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!

АЧЫК, ТӨГӘЛ

ЖЫРЧЫ ГАБДУЛЛА ...

ЖЫРЧЫ АЛЬБЕРТ ...

СПОРТ ТӨРЕ

1

АЗИЯДӘ ИСЛАМ ДӘҮЛӘТЕ

10

ФЛОТ ӨЧЕН УРМАН КИСҮЧЕ

...(-1)-ТУАР

НЕМЕЦ ФИЗИГЫ

ХАЛЫК ЖЫРЫ

13

«... КАЕН»

...-СУ

САМОЛЁТ

... — КҮП

«АЛТЫН ...»

ШӘҺӘРӘТ

14

КАМА ... РАЙОНЫ

5

6

УСАЛ ӘКИЯТИ ЗАТ

ЖИР АСТЫНДА АЛТЫН ...

"ӘЗЕР БУЛ!"

БӘЯ БИРҮ БЕРӘМЛЕГЕ

НОТА

МАУГЛИНЫҢ ДУСТЫ

ӘЙТКӘН СҮЗ

ХУШ ...

"КАРА ДА ГЫНАЙ АЙ, ТУЗ БАШЛЫ"

ТАТАРСТАН — ДУСЛЫК ...

НӘСЕЛ, ТОКЫМ

"ӘРЕМ ..."

9

2

7

"... ЖЫЛЫ КОЧАГЫ"

ТӘМЛӘТКЕЧ ҮСЕМЛЕК

ХУШБУЙ

"САБАКЛАРЫ ЖИРГӘ ..."

"... МАРШ" (МАЯКОВСКИЙ)

11

РАБИТ ...

ИКЕ УРМАН АРАСЫ

"... МИНЕМ ГАЗИЗ ХАЛКЫМ"

365 көн

"... ГӨЛ"

"... ТРАГЕДИЯСЕ" (ТАКТАШ)

3

КЕШЕНЕҢ УЙЛЫЙ ТОРГАН ОРГАНЫ

4

ЯКЫН ТУГАН

... БАҺМАНОВ

(-1) РИЗЫКНЫҢ ТӨП СЫЙФАТЫ

ТРАКТОР МАРКАСЫ

... АЛИШ

ТУГАН ...

15

РЕЖИССЁР МАРСЕЛЬ ...

8

12

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Шкаф-купеның ишеген алып куйсаң, нәрсә килеп чыга?

2. Бюрократларның профессиональ чире.

3. Ни өчен кешеләргә караганда этләрне ныграк яраталар?

4. Нәрсә ул компромисс?

5. Бакчасы, дачасы, жир кишәрлеге булмаган кешеләргә язын нишләргә кирәк?

6. Пессимист белән оптимистның аермасы нәрсәдә?

7. Ирләрнең тормышларындагы иң бәхетле вакытлары кайчан?

ЖАВАПЛАР

1. Шкаф-плацкарт. 2. Документлар белән эш итү. 3. Чөнки этләр койрык кына болгыйлар, сүз болгатмыйлар... 4. Осталык. Пирог булгәндә һәр кеше үзенә иң зур кисәк эләкте дип хис итә. 5. Үзендә казыну. 6. Пессимист күкедән үзенә күпме гомер яшисен сорый, ә оптимист – тукраннан. 7. Әти-әнисеннән, хатыныннан рөхсәт сорау кирәкмәгәндә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 5 нче санында басылган чаянвордның тикшеру сүзе – **«САЛАГЫШ БОЛЫННАРЫ»**

Беренче булып дөрес жавап жибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Жиңүчебез – Апастан **Зәйнәп ЯРУЛЛИНА!**









Эрнест ДЫШАЕВ

Александр АЛЁШИН



